# Кунакка чакыру







Сорауларны укыйбыз,җавап бирәбез.

“А”

-Төлке белән Торна ничек яшиләр?

-Төлке кемне кунакка чакыра?

-Ул нәрсә пешерә?

-Ботканы кем ашый?

“Б”

-Торна кемне кунакка чакыра?

-Ул нәрсә пешерә?

-Торна нәрсә ди?

-Ни өчен Төлке белән Торнаның дуслыгы бетә?

# КУНАКТА ҮЗЕҢНЕ ТОТУ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

- **Үзеңне тыныч тотарга кирәк. Кычкырып сөйләшергә ярамый.**
- **Матур итеп,чиста-пөхтә киенеп килергә кирәк. Ямьсез киенеп кунакка бармыйлар.**
- **Хуҗалар белән әдәпле итеп исәнләшәләр,матур итеп күчтәнәчләрне, бүләкләрне тапшыралар.**
- **Өстәл артында алдыңа куелган тәлинкәдән генә ашыйлар. Кеше алдына үрелеп утырмыйлар.**
- **Берәр әйбер кирәк булса, зинһар өчен  алып бирегез дип сорарга кирәк.**
- **Өстәл артыннан кузгалганда рәхмәт әйтә белергә кирәк.**
- **Өйгә кайтканда хуҗаларга рәхмәт әйтеп, саубуллашып кайтып китәргә кирәк.**

# Тылсымлы сүзләр

- **Исәнмесез.**
- **Хәерле көн.**
- **Рәхим итегез.**
- **Зинһар өчен.**
- **Рәхмәт.**
- **Таныш булыгыз.**
- **Гафу итегез.**
- **Кичерегез.**
- **Керергә мөмкинме?**
- **Туган көнең белән.**
- **Ашыгыз тәмле булсын.**
- **Безгә кунакка килегез.**
- **Сау булыгыз.**
- **Хәерле юл.**



# МӘКАЛЬЛӘР

- Кунак ашы - кара каршы.
- Кунак булсаң - тыйнак бул.
- Кунакка барсаң, кунак көт.
- Яхшы ашка - кыстау кирәкми.

# Татар халык ашлары





# 3-2-1.

- 3 Ошады:
- 2 Ошамады:
- 1 Аңламадым:

# ӨЙ ЭШЕ

- ”Кунакта” дигән темага диалог язып килергә.